Үзәкләштерелгән дини оешма

РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ

Һиҗри календарь буенча 1446 елның Изге Рамазан ае башлануы уңаеннан Россия Федерациясе мөселманнары диния нәзарәте рәисе баш мөфти шәех Равил Гайнетдиннең мөрәҗәгате (2025 елның 1 марты)

Мәскәү
2025 елның 1 марты
1446 Һиҗри елның 1 Рамазаны

بِسْمِ ٱللَّهِ ٱلرَّحْمَٰنِ ٱلرَّحِيمِ

بسم الله الرحمن الرحيم
الحمد لله رب العالمين
والصلاة والسلام على رسول الله
وعلى آله وصحبه اجمعين
وبعد
السَّلَامُ عَلَيْكُمْ وَرَحْمَةُ ٱللَّهِ وَبَرَكَاتُهُ

Сезгә Аллаһы Тәгаләдән иминлек,
Аның рәхмәтен һәм бәрәкәтен сорыйм, кадерле дин кардәшләрем!

Кадерле кардәшләрем! Сезне изге Рамазан ае башлануы белән котлыйм!

Әлеге ай барыннан да элек ураза ае буларак билгеле, әмма ул башка мөһим билгеләрне дә үз эченә ала. Бу изге айда без шуны онытмаска тиеш: уразаның төп максаты ашау-эчүдән тыелу гына түгел, ә үзебезнең нәфесне тәрбияләү.

Аллаһ әйтте:

قَدْ أَفْلَحَ مَن زَكَّاهَا وَقَدْ خَابَ مَن دَسَّاهَا

«Аны пакълаучы котылды, һәм аны яшергән кеше зыян күрде» («Әш-Шәмс» сүрәсе, 9–10 аятьләр). Һәм бу авыр эштә уңышка ирешү өчен күп көч куярга кирәк.

Ураза тоту, Коръән Кәримне уку, игелекле гамәлләр кылу, туганлык мөнәсәбәтләрен саклау, садака бирү — болар барысы да күкләрне һәм җирне яраткан Раббыбызга якынайта.

Бу рәттә гыйбадәт аерым урында тора. Рус телендә гыйбадәт намазны да, доганы да берләштерә. Рамазан аенда гыйбадәтнең бу ике төре дә гаять әһәмиятле һәм кыйммәтле.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: ***«Рамазан аенда иман һәм күндәмлек белән намаз укыган кешенең гөнаһлары кичереләчәк»***, — дигән (Бохари, Мөслим). Төнге намазлар аеруча кыйммәтле, чөнки кеше үзен йокы ләззәтеннән биздереп, бу вакытны Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәттә уздырырга ниятли.

Әле намазга басмаганнарга Рамазан ае аны укый башлау өчен яхшы этәргеч. Әмма берәрсе намаз укымый икән, бу Аллаһка мөрәҗәгать итү мөмкинлеге киселгән дигән сүз түгел. Гарәп телен белмичә дә, Аллаһка мөрәҗәгать итәргә мөмкин. Дога — чын күңелдән, йөрәк түреннән чыккан сүзләр белән Аллаһка ялвару ул, чөнки дөньядагы бар телләрне Раббыбыз яралткан, ул безнең бар уйларыбызны, сүзләребезне һәм ниятләребезне белә.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм тарафыннан аеруча билгеләп үтелгән, гарәп телендә уку бик хуплана һәм мактала торган мөрәҗәгатьләр

дә бар. *«Әллаһүммә иннәкә гафүввүн кәримүүн түхиббү-л-гафвә фәгъфү ганнәә»* (Әй Раббым, Син Гафу итүче, Юмарт, Син гафу итүне яратасың, безне дә гафу ит) — шундый догалардан. Әмма гади, үз сүзләрең белән әйтелгән, ләкин һичшиксез, ихлас күңелдән ялварган дога да кешеләрнең хәлен үзгәртергә мөмкин, әлбәттә, ул Аллаһ тарафыннан кабул ителсә.

Балигъ булган һәм үз акылында булган мөселманнар өчен уразаның фарыз булуын ассызыклап, кешенең физиологик мөмкинлекләренә объектив бәяләүне дә, аерым алганда, хроник авырулардан интегүче кешеләр барлыгын да истә тотарга кирәк. Раббыбыз безне төрле итеп яраткан — кемгәдер Ул күбрәк көч биргән, ә кемгәдер азрак. Шуннан чыгып һәм шулай ук **«Аллаһ җиңеллек тели, авырлык теләми»** («Әл-Бәкара» сүрәсе, 185 аять) дигән аятькә таянып, мөселманнарны үз сәламәтлекләренә гакыллы бәя бирергә чакырам.

Хәдисләрнең берсендә Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең сәхабәләрен мондый сүзләр белән нәсыйхәтләгән: «Күтәрә алырдай эшләргә генә тотыныгыз, хакыйкатьтә, алар Аллаһны туйдырмас, мәгәр, үзегез алардан туйганчы» (Бохари). Бу хәдиснең дәвамында әйтелгәнчә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм әз генә вакыт сарыф ителсә дә, тырышлык куеп кылынган доганы бигрәк тә яраткан. Кызганыч, кайвакыт өстәмә һәм мәҗбүри күрсәтмәләрне үтәүдә акылсыз ашкыну кыенлыкларга китерә. Һәм бу еш кына карарларыбыз һәм гамәлләребезнең ахыры турында уйламаганлыктан килеп чыга.

Мәсәлән, кемдер хроник авыруы аркасында уразаны тулысынча үти алмый. Шулай да ул үзен кызганмыйча, бу фарызны үтәргә тырышырга тиешме? Кайвакыт хәтта диабет диагнозлы һәм башка җитди авырулардан интегүче кайбер дин кардәшләребез ураза тота башлый, шуннан соң аларны ашыгыч ярдәм машинасында алып китәләр. Андый гамәлләр Аллаһка кирәкме? Аллаһның динендә җитди сәбәпләр белән ураза тотмаган көннәрне каза кылу, ягъни кире кайтару мөмкинлеге бар.

Әмма бу ураза тота алмаучылар өчен Рамазан аеның кыйммәте кими дигәнне аңлатамы? Һич тә юк! Ураза тота алу мөмкинлеге булу яки булмауга карамастан, Рамазан ае барыбер үзенең кабатланмас һәм үзенчәлекле мәгънәсенә ия булып кала. Шуңа күрә кешеләргә гадәттә эшләгән иң яхшы гамәлләрен бу изге айда тагын да күбрәк итеп башкарырга кирәк.

Кадер кичәсен («Ләйләтү-л-кадер») аеруча билгеләп узарга кирәк. Бу төн — «мең айдан да яхшырак», ә мең ай — ул 83 елдан артык! Бу төннең бәрәкәте чиксез, шуңа күрә Аллаһның Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләм Кадер кичәсен Рамазан аеның соңгы төннәрендә эзләргә өндәгән. Нәкъ менә эзләргә, чөнки ул һәрвакытта да 27 нче төндә булмый. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең мондый әмере һич тә очраклы түгел: әгәр бу төннең төгәл датасы билгеле булса, күпләр, мөгаен, алдагы һәм киләчәк көннәр белән төннәр турында артык кайгырмыйча, шул вакытны гына көтеп торыр иде. Безгә Кадер кичәсенең мөмкин булган даталары, мәсәлән, Рамазанның соңгы ун так төнендә, дип күрсәтелүдә зирәклек бар.

Шулай итеп, бу бәрәкәтле төн җиткәнне көтеп кенә калмыйча, аны эзләргә, тырышлыгың белән ирешергә кушыла. Кем дә кем бу төнне догада үткәрә икән, Аллаһ теләсә, ул Раббысының кичерүенә һәм мәрхәмәтенә өмет итә ала, чөнки Коръәндә болай диелгән:

لَا تَقْنَطُوا مِن رَّحْمَةِ اللَّهِ إِنَّ اللَّهَ يَغْفِرُ
الذُّنُوبَ جَمِيعًا إِنَّهُ هُوَ الْغَفُورُ الرَّحِيمُ

«Аллаһның рәхмәтеннән өмет өзмәгез. Чөнки Аллаһ гөнаһларның барысын да гафу итә, һичшиксез, Ул — Гафу итүче, Рәхимле» («Әз-Зүмәр» сүрәсе, 53 аять).

Шулай итеп, Рамазан ае ураза һәм гыйбадәтләр ае булып санала, әмма бу чорда мөселманнарның актив тормышы туктала дигән сүз түгел. Киресенчә, һәр ел саен бу изге айда без тормышыбызга безне үстерә һәм алга этәрә торган ниндидер яңа һәм файдалы үзгәреш кертергә тиеш.

Әйтик, инде 45 ел дәвамында Рамазанның соңгы җомгасында бар дөнья мөселманнары Бөтендөнья әл-Кудс (Иерусалим шәһәренең гарәпчә атамасы шундый) көнен билгеләп үтә. Әлеге дата Иран Ислам Республикасына нигез салучы һәм аның беренче җитәкчесе, аятолла Хомейни тарафыннан әле 1979 елда ук Фәләстыйн халкы белән теләктәшлек йөзеннән игълан ителде. Соңгы елларда әл-Кудс көне Иран чикләреннән ераккка чыкты һәм бар мәзһәб мөселманнарын гына түгел, ә төрле инанудагы һәм төрле фикердәге кешеләрне дә берләштерә. Һәм бүген, Фәләстыйн белән бар Якын Көнчыгыш халкы җилкәсенә төшкән авыр сынаулар чорында, бу көн моңарчы булмаганча әһәмиятле, чөнки бердәмлек һәм ныклык кына мөселман, христиан кардәшләребезнең туган җирләре — Фәләстыйн Газасыннан куылдырмый кала ала.

Якынлашып килүче Рамазан ае мөселманнар үзләренең таркаулыкларын җиңеп, бер-берсенә сүзләр белән генә түгел, ә гамәлдә дә ярдәм итә башлаган ай булсын.

Без Аллаһтан җирдәге тормышыбыз өчен дә, мәңгелек өчен дә файдалы һәм бәрәкәтле Рамазан сорыйбыз! Йортларыбызда, Ватаныбызда тынычлык, үзара килешү, бәхет һәм иминлек булсын! Аллаһ бу айда мохтаҗларны тукландыру өчен малын фида кылучыларның барысына да бәрәкәтен бирсен! Бигрәк тә без Раббыбыздан кардәшебез Сөләйман Әбүсәид улы Кәримов өчен догада торабыз, аның юмартлыгы нәтиҗәсендә меңнәрчә һәм дистәләгән мең кеше кайнар ифтар ризыгы һәм азык-төлек җыелмалары алачак.

اللهمّ خفّف عنّا ثقل أوزارنا، وارزقنا عيشة الأبرار،
واكفِنا واصرف عنّا شرّ الأشرار، وأعتق رقابنا ورقاب آبائنا
وأمّهاتنا وعشيرتنا من عذاب القبر ومن النّيران، برحمتك يا أرحم الرّاحمين.

Йә Аллаһ, безнең өчен авырлыкларны җиңеләйт, безгә тәкъваларның гомерен насыйп ит, безне сакла һәм имансызларның явызлыгын безгә тигезмә, безне коткар, шулай ук ата-аналарыбыз һәм туганнарыбызның җаннарын кабер газапларыннан, җәһәннәм утыннан коткар, ий Рәхимлеләрнең Иң Рәхимлесе! Әмиин!

Баш мөфти, шәех Равил Гайнетдин,

Россия Федерациясе мөселманнары диния нәзарәте рәисе